**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422700, ТР Биектау районы, Биектау тимер
юл станциясе поселогы, Совет урамы, 13

**СОВЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
422700, Высокогорский район РТ,
п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82,e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**27 май 2015 ел**

**РЕШЕНИЕ**
**№ 188**

## Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы 2014 нче елның 11 нче ноябрендәге 152 нче «Физик затлар милкенә салым турында» Карарына үзгәрешләр кертү турында.

Россия Федерациясе Салым кодексының 32 нче бүлеге, 2014 нче елның 30 нчы октябрендәге 82-ТРЗ номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым буенча салым базасын салым салу объектларының кадастр бәясеннән чыгып билгеләү тәртибен Татарстан Республикасы территориясендә куллана башлауның бердәм датасын билгеләү турында» Татарстан Республикасы законы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советы

## КАРАР КЫЛДЫ:

1. Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Советының 2014 нче елның 11 нче ноябрендәге 152 нче номерлы «Физик затлар милкенә салым турында» Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2 нче пунктта:

а) 1 нче пунктчада:

түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

мәйданы 30 квадрат метрдан артмаган һәм Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 нче статьясындагы 7 нче пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларында, шулай ук Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 нче статьясындагы 10 нчы пунктындагы икенче абзацында каралган салым салу объектында урнашкан гаражлар һәм машина-урыннар «Ставкасы бер гаражга яки машина-урынга карата салым түләүченең теләге белән билгеләнә.»;

б) 4 пунктчада:

икенче һәм өченче абзацларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

в) түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) 2015 нче елда-1,5 процент, 2016 нче елда - 1,8 процент, 2017 нче елда - 2 процент һәм алдагы елларга карата-2 процент:

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 нче статьясындагы 7 нче пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектлары;

Россия Федерациясе Салым кодексының 3782 нче статьясындагы 10 нчы пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата»;

1.2. Түбәндәге эчтәлекле 3 нче пункт өстәргә:

«3. Ике фатирдан торган күп фатирлы торак йортта фатирга милек хокукы булган физик затларга әлеге фатирның гомуми мәйданының утыз квадрат метрының кадастр бәясендәге салым ставкасының процент өлеше буларак билгеләнә торган суммага исәпләнгән салым суммасын киметү рәвешендә ташламалар билгеләргә.

Әгәр фатир гомуми өлешле милектә булса, ташламаларның суммасы өлешле милектә катнашучыларның һәркайсы өчен әлеге фатирга милек хокукында пропорциональ рәвештә исәпләнә.

Әгәр фатир уртак милектә булса, ташламалар суммасы уртак милектә катнашучыларның һәркайсы өчен тигез өлешләрдә исәпләнә.

Бу очракта әлеге пункт нигезендә исәпләнгән ташламалар суммасы аны исәпкә алмыйча исәпләнгән салым суммасыннан артып китә алмый".

1.3. 3, 4, 5 һәм 6 нчы пунктларны 4, 5, 6 һәм 7 нче пунктлары дип санарга.

2. Әлеге карар 2015 нче елның 1 нче гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми интернет-порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Красносельский авыл җирлеге башлыгы урынбасары Р.Р. Никитенкога йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районының
Красносельский авыл җирлеге Башлыгы Р.Г.Кәлимуллин